Алга, белем иленә!

# Мәктәбем минем

Казан шәһәре Идел буе районының 78 нче лицей «Фарватер»
укучыларының нәфис басмасы

2019 нчы ел
№ 2



Әлеге санда

Көтеп алган Яңа ел
(2 нче бит)

Яңа елда—яңа җиңүләр!
(3 нче бит)

Театр яктылыкка, нурга илтә
(4 нче бит)

Россиядә театр елы
(5—7 нче битләр)

Китапханәдәге үзгәрешләр
8 нче бит)

Илһам канатында
(9 нчы бит)

Бәйгедә катнаш һәм бәйге от!
(10 нчы бит)

## ЯҢА ЕЛ БЕЛӘН !

Ниһаять, Яңа 2019нчы ел килеп җитте! Олысы-кечесе яраткан әлеге бәйрәм уңаеннан иң изге теләкләрне кабул итегез. Без 2018 елны аның шатлыклары, тормышыбызда булган уңышлары, куанычлары белән искә алабыз. Шул ук вакытта, узып баручы елда тормышка ашырылмаган эшләребез һәм хыялларыбыз барлыгын да онытырга ярамый!

Узган елдагы вакыйгалар арасында, әлбәттә, укучыларны һәм укытучыларны сөендергәннәре дә, көендергәннәре дә булгандыр. Иң мөһиме — без үз язмышыбыз өчен җаваплы була алдык һәм төрле сынауларны сабырлык һәм түземлек белән лаеклы уздык.

Кадерле укучыларыбыз! Сезне чын күңелдән яңа 2019 нчы ел белән котлыйбыз! Җир өстенә аклык-пакьлек алып килгән Яңа ел бәйрәме котлы булсын! Киләсе елның 365 көне дә бәхет-шатлык кына китерсен. Аткан таңнарның барысы да алсу булсын. Тормыш юлларында шатлыклы очрашулар, бәхетле елмаюлар, куанычлы мизгелләр күп булсын! Быел барлык теләкләрегез чынга ашсын, куйган максатларыгызга ирешергә язсын! Безнең белән бергә булыгыз!

## ЯҢА ЕЛ БӘЙРӘМЕННӘН БЕРНИЧӘ МИЗГЕЛ:)



*Матвейчева Анастасия, 6 А*

## ЯҢА ЕЛДА ЯҢА УҢЫШЛАР!

Яңа ел үзенең яңалыклары, яхшы хәбәрләре белән безне сөендереп тора. Җиңүчеләребезгә алга таба да зурдан-зур уңышлар телибез!





Район күләмендә үткәрелгән «Ватан нәрсәдән башлана?» исемле нәфис сүз осталары конкурсында җиңүчеләр:

**Мәрдәнова Гүзәл, 6 нчы сыйныф;**

**Фәритова Эльвина, 4 нче сыйныф;**

**Кәримуллина Адилә, 8 нче сыйныф.**






“Казан сандугачы” район бәйгесендә җиңүчеләр:

**Сәгъдиева Диләрә, 4 нче сыйныф;**

**Хөснетдинова Алия, 7 нче сыйныф.**

Т. А. Геллер истәлегенә багышланган «XXI гасырда әдәбият белеме һәм эстетика» XVI Бөтенроссия фәнни – гамәли конференциясе җиңүчеләре




**Зарипова Арина, 9 нчы сыйный;**

**Семенова Снежана, 9 нчы сыныф.**

«Йолдызлы билет» исемле шигырь укучылар конкурсының район этабында җиңүчеләр:

**Галеев Марсель, 2 нче сыйныф;**

**Галимҗанова Камила, 2 нче сыйныф.**




*Алиев Мурад, 10 Б*

## 2019 - ТЕАТР ЕЛЫ!

Театр сәнгатен алга таба үстерү максатыннан Россия Федерациясендә 2019 ел – Театр елы дип игълан ителде. Безнең укучыларыбыз театрларга еш йөриме, шул турыда танышып үтик.



- Без сыйныфташларым белән “Әкият” курчак театрына бардык. “Цветик-семицветик” спектакле миңа һәм дусларыма бик ошады. (Репеева Алёна, 1 нче сыйныф).



- Казанның Василий Качалов исемендәге рус зур драматик театрында, Яшь тамашачы театрларында булганым бар. Ләкин, спектакльләргә караганда киноны якынрак күрәм. 2019 нчы ел—Россиядә театр елы, шуңа берничә спектакль карарга барырга теләк бар. (Алиев Мурад, 10 нчы сыйныф).




- Яшь тамашачылар театрына, Василий Качалов исемендәге рус зур драматик театрга, Болактагы яшьләр театрына бик яратып йөрим, шулай да иң яратып йөргән театрым – Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театры. Театр үзенчәлекле спектакльләре, бинаның төзелеше белән бик кызыклы. (Степанова Арина, 10 нчы сыйныф).

*Скичко Артём, 10 Б*

# ЯЛ КӨННӘРЕНДӘ КАЯ БАРЫРГА

Театр елы уңаеннан, газетабыз битләрендә, шәһәребездә урнашкан театрлар белән танышырга мөмкин. Бу эшебезне алдагы саннарда да дәвам итәрбез.

## ГАЛИӘСКАР КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ



1922 елда асылда «Сәйяр» труппасы нигезендә һәм аңа төрле яклардан, төрле труппалардан артистлар, драматурглар, музыкантлар җыелу нәтиҗәсендә дәүләт театры төзелә. Ул «Кызыл Октябрь исемендәге беренче татар дәүләт үрнәк драма театры» дип атала, аның җитәкчесе итеп, драматург К. Тинчурин билгеләнә. 1926 елда театр Академия исеменә лаек була, ә 1939 елда Галиәсгар Камалның 60 еллык юбилее уңае белән театрга аның исеме бирелә. 1986ның 5 ноябрендә театрның яңа бинасы тантаналы рәвештә ачыла.

## КӘРИМ ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕТРЫ



Югары профессионал дәрәҗәдәге әзерлек, чарланган уйнау осталыгы, драматургия һәм бүгенге чынбарлыкны яхшы белү — болар барсы да К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакльләренең үзгә яклары. Шуның өчен аларны халык үз итә һәм ярата.

1988 ел театр тарихында кискен борылыш чоры була. Шул елны театрга, бөек татар артисты, режиссеры, драматургы К.Тинчурин исеме бирелә һәм М.Горький урамы 13 йорт адресы буенча урнашкан бинага күчә.


## КАЗАН ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ РУС ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ



Василий Качалов исемендәге Казан дәүләт академия рус Зур драма театры — Казан шәһәрендә урнашкан рус театры, Русиянең иң иске театрларының берсе.

Беренче тапкыр 1791 елда Казанда сәнгать сөючеләре труппага җыела. 1803 елда махсус төзелгән бинада профессиональ төркем чыгыш ясый башлый. Хәзерге бинада театр 1914 елдан бирле урнаша. Тамашачылар залы 505 кешене сыйдыра.

## КАЗАННЫҢ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ



Казан яшь тамашачы театры –Казан шәһәрендә эшләүче дәүләт театры. Яшүсмерләр һәм яшьләр өчен рус телендәтамашалар куя. Театр югары һөнәри режиссурасы һәм артистларның талантлы уены белән аерылып тора.

Габдулла Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры тарихы 1987 елдан башлана. Ул башта Татарстан Мәгариф министрлыгы каршында Татар театр-студиясе буларак оештырыла.

1991 елда театр «дәүләт» статусы ала һәм аңа «Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры» дигән исем бирелә

Казан Татар Дәүләт яшь тамашачы театрына 2007 елның 16 февралендә Татар театрына нигез салучы артист һәм режиссер Габдулла Кариев исеме бирелә.

*Миндубаева Альбина, 5А*

## КАЗАН ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ РУС ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ



Китапханәсез мәктәпне күз алдына китерүе кыен. Мәктәп китапханәсе һәр укучының төп таяну ноктасы булып тора.

Яңа уку елында китапханәбез зур үзгәрешләр кичерде. Һәр укучы, килгән һәр кунак китапханәбезгә югары бәя бирә.

Китапханә - серләр дөньясы. Китапханәчебез Вирцева Ирина Михаил кызы – шушы серле дөньяның хуҗасы. Барлык укучылар да ярткан, хөрмәт иткән Ирина Михайловна кем соң ул? Нинди кеше? Бу сорауларга җавап табу өчен, без турыдан – туры Ирина Михайловнаның үзенә мөрәҗәгать иттек.



**- Ирина Михайловна, китапханәбездә булган үзгәрешләргә сез ничек карыйсыз?**

- Минем өчен иң мөһиме – яңа китапханәбезнең укучыларыбызга ошавы.

**- Үзегез турында берничә сүз.**

- Укырга мин һәрвакытта да яраттым. Хисле кеше буларак, әсәрләрне елап, көлеп укыйм. 6 яшемә кадәр мин әбиемдә яшәдем, китапларга булган мәхәббәтемне дә нәкъ менә әбием уятты. Ул әсәрләрнең эчтәлеген, җырлар, табышмклар, мәкаль-әйтемнәр белән бизәп сөйли иде.



Әдәби әсәрләргә мәхәббәтем көчле булса да, беренче белемем буенча мин заводта эшләдем. 90 нчы елларда техник һөнәремне китапханәче һөнәренә алыштырдым, һәм моңа бер дә үкенгәнем юк. Безнең лицейда 17 ел эшлим.



**- Ирина Михайловна, балалар белән эшләүнең үзенчәлеге нидән гыйбарәт?**

- Балалар белән эшләү – миңа бетмәс көч бирә. Иң мөһиме китапханәгә укучылар күзлеге белән карарга, гел яңалыкка омтылырга кирәк.




**- Беребезгә дә сер түгел, укучылар китапханәгә яңа китап артыннан гына түгел, сез оештырган бик күп конкурсларда да катнашырга йөриләр. Шушы кокурслар турында да берничә сүз әйтеп китсәгез иде.**

- 2019 нчы ел – Россиядә театр елы, шушы вакыйга белән бәйле бик күп кызыклы мероприятеләр көтелә. Бүгенге көндә Яңа ел белән бәйле конкурс дәвам итә.

**- Укучыларга нинди китаплар киңәш итәр идегез.**

- Сүзлекләр һәм справочную әдәбият, классик әсәрләр һәм әлбәттә инде, үзең мавыккан китапларны укырга киңәш итәм.

**- Электрон китапларга ничек карыйсыз?**

- Бар нәрсәнең дә уңай һәм тискәре яклары була. Гел компьютер, планшет, гаджетлардан уку да күзләрне боза, ләкин XXI нче гасырда кәгазь китаплар белән генә файдалану да отышлы түгел.



**- Кешеләрдә иң яраткан сыйфатыгыз?**

- Эчкерсезлек, яхшылык.

**- Сезнең теләкләрегез.**

- Һәр кеше дә китапханәгә юлны белергә тиеш!

**- Әңгәмәгез өчен бик зур рәхмәт! Сезгә алга таба да уңышлар телибез!**

*Инсафетдинов Эмиль, 10 Б*

## КЫШКЫ МАТУРЛЫК

Кыш җитте, дуслар,
Сөенәм мин шуңа.
Ябалактай карлар,
Иңнәремә куна.



Бөтен дөнья ап-ак
Мамыкка күмелгән.
Агачлар, куаклар
Шәлләргә төренгән.

Шәһәрдә шундый күп,
Биек кар таулары.
Күңелле шул бергәләп
Таулардан шуулары.

*Низамова Азалия, 4 В*

## ТАПКЫР БУЛСАҢ, ТАБЫШМАКЛАР ЧИШ

Аягы юк – китәр,
Җибәргән җиргә җитәр,
Кушкан йомышны үтәр.

Кышын ята таштай,
Язын чаба аттай.

Кабат-кабат,
Бер кошта өч йөз алтмыш биш канат,
Мин торам аны санап,
Көн дә кими бер канат.

Аягы юк, кулы юк,
Сөйләшергә теле юк,
Кояш кебек нуры юк,
Күрергә күзе юк,
Һич җитмәгән җире юк.

Мыр-мыр мырлысы,
бик каты икән борнысы.

Кешенең дусты, йортның сакчысы.

# Бәйге!

**Кагыйдә**

Рәсемдәге буш урынга кызыклы комментарий уйлап тап һәм жавабыңны 117 нче кабинетка хәбәр ит.

Дуслар, иң кызык комментарий авторын бүләк көтә!



## 2 нче Г сыйныф укучыларының иҗаты



Жукова Виктория



Кутрунова Карина



Николаев Михаил



Сабиржанова Диләрә



Кутрунова Карина



Казакова Таисья

Безнең адресыбыз: Казан шәһәре Идел буе районы «78 нче лицей «Фарватер»

(Ю.Фучик урамы, 40 нчы йорт), 420139 тел./ факс 268-58-61.

E-mail: school_7878@mail.ru

Газетабызны түбәндәге сайттан күрергә мөмкин: https://edu.tatar. ru/priv/school78.htm/ page813169. htm

**Мөхәррир:** *Инсафетдинов Эмиль,*
*Алиев Мурад,*
*Миндубаева Альбина*
*Матвейчева Анастасия*

***Консультант:*** *Фәйзуллина Рәзилә Яудәт кызы.*